**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 190-20 «14» декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 28 маендагы 194-29 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә һәм бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге принцибын үтәүне тәэмин итү һәм республика законнары нормаларына туры китерү максатыннан,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 28 маендагы 194-29 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 7.1 пункт өстәргә:

«7.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата түләү муниципаль хезмәткәрнең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла.

Күрсәтелгән бурычны пенсиягә өстәмә билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салганда пенсиягә өстәмә түләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга:

http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин